СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

НУРЛАТ РАЙОНЫ ИЖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА НУРЛАТСКОГО РАЙОНА.

11 декабрь, 1998 ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 141 (8298) | Бәясе билгеләнгәнчә

## *Бар да укый, белем ала*
## КОЧЕГАРЛАР...

"Агропромэнерго" берләшмәсе базасында район хуҗалыклары фермалары, мәктәпләренең сыек ягулык һәм күмер белән ягыла торган котельняларында эшләүче кочегарлар өчен укулар үткәрелде. Ике көн дәвамында барган бу укулар белгечлек буенча яңабаштан аттестацияләү тәртибендә иң кирәкле һөнәри белемнәрне яңартырга булышты.

## БАШ ЗООТЕХНИКЛАР, БАШ ИКЪТИСАДЧЫЛАР...

Чәршәмбе көнне "Нурлат - Октябрь элеваторы" клубында район хуҗалыкларының баш зоотехниклары, баш икътисадчылары семинар - укуга җыелдылар. Төп тема - зоотехник учетны тәртипкә салу һәм икътисадый анализны бүгенге көн таләпләреннән чыгып алып бару буенча конкрет тәкъдимнәр, эшлекле күрсәтмәләр белән тыңлаучылар алдында авыл хуҗалыгы һәм азык - төлек идарәсе начальнигы Ф.М. Дәүләтшин һәм идарәнең терлекчелек бүлеге начальнигы Р.И.Сиражетдинов чыгыш ясадылар.

## БАШ ИНЖЕНЕРЛАР

"Сельхозтехника" район берләшмәсе базасында хуҗалыкларның баш инженерлары белән шулай ук эшлекле сөйләшү үтте. Аны берләшмә белгечләре белән берлектә "Гостехнадзор" инспекциясе начальнигы Р.С.Сатдаров уздырды. Киңәшмәдә төп сүз авыл хуҗалыгы техникасын ремонтлауның барышы турында барды, аны оештыруда "Сельхозтехника" берләшмәсе белән элемтәне киңәйтү зарурлыгы ассызыкланды.




*Зур "Өмет" агрофирмасының күпсанлы механизаторлары арасында аларның үз бәясе, үз дәрәҗәсе бар. Петр Георгиевич Петров көпчәкле Т - 150 тракторында быел чәчү өчен җир әзерләүдә иң югары нәтиҗәгә иреште. Хәзер ул кукуруздан кыйммәтле азык - он әзерләүчеләр составында: басудан чәкәннәрне ташып тора. Николай Васильевич Маськин исә иң күп уҗым чәчүчеләр исемлегендә хөрмәт белән билгеләп үтелде. Хәзер ул җәмәгать терлекчелегендә: кырдан салам тарттыра. Тәҗрибәле механизаторларга шулай елның һәр фасылында да эш табылып тора. Билгеле, һәр наряд җиренә җиткереп үтәлсен, күрсәткечләрнең дә иң югарылары тәэмин ителсен дигәндә үз "корыч айгырларын" да гел карап - майлап йөртергә туры килә. Бу яктан да алар - күпләр өчен үрнәк. Шуңа үзләре эшләп торган Мичурин исемендәге КХА биләмәләре киңәеп, "Өмет" агрофирмасы булып үзгәртелгәч тә үз позицияләрен бирмәскә, даннарын җуймаска тырышалар.*

*Рәсемдә: механизаторлар П.Г.Петров, Н.В.Маськин.*

## 12 ДЕКАБРЬ - ШӘҺӘР КӨНЕ

### *Хөрмәтле нурлатлылар!*




*12 декабрь көнне ипподром мәйданында "Шәһәр көне"нә багышланган зур бәйрәм була.*

*Бәйрәмнең программасы түбәндәгечә:*

*1. Бәйрәмне тантаналы ачу.*

*2. Спорт ярышлары һәм спорт - күңел ачу уеннары.*



*3. Нурлат шәһәре призына Мәскәү, Казан, Түбән Кама, Яр Чаллы, Тольятти, Ижевск, Ульяновск, Самара шәһәрләреннән Россиянең иң көчле спортчылары катнашында кышкы трек автомобиль узышлары. Аннан соң стартка "Буран"нар басачак (ярышка чыгарга теләүчеләр хәзердән теркәлергә тиешләр).*

*4. Сәүдә предприятиеләре - Нурлат район кулланучылар җәмгыяте, "Нурлатнефть" НГДУсы, тимер юл һәм урман хуҗалыгы эшчеләрне тәэмин итү бүлекләре, район хуҗалыклары һәм предприятиеләре кибетләре, шәхси эшмәкәрләр, җәмәгать туклануы предприятиеләре сатучылары катнашында зур ярминкә.*

*Бәйрәмдә пар атларда мәйдан әйләнү мөмкинлеге булачак. Иң җитез һәм матур бизәлгән атларга урыннар билгеләнәчәк. Ярминкәдә иң мул товар белән катнашкан һәм сәүдә нокталарын матур итеп бизәп, халыкка культуралы хезмәт күрсәткән сәүдә оешмалары һәм хуҗалыкларга да махсус урыннар каралган.*



*Бәйрәм 9.00 сәгатьтә башлана.*

*11 декабрь көнне автоузышларда катнашучылар өчен контроль үтү билгеләнә.*

*Хөрмәтле нурлатлылар, кунаклар! Шәһәр көненә рәхим итегез!*

### *Рәсми хәбәрләр*

## БЕР КӨНДӘ - ИКЕ ҖЫЕЛЫШ

7 декабрьдә "Нурлат" агрофирмасының **"Рассвет"** КХАсы әгъзаларының гомуми җыелышы булды. Анда оештыру мәсьәләсе каралды. Җыелыш, башка эшкә күчерелүе сәбәпле, хуҗалык рәисе Ә.Н.Рәхмәтуллинны вазифаларыннан азат итте. Хуҗалык рәисе итеп моңарчы Хафизов исемендәге КХА рәисе булып эшләгән **Валерий Федорович Булатов** сайланды.

Җыелышта район хакимияте башлыгы Ф.С. Сибагатуллин һәм "Татмясопром" холдинг компаниясе президенты Ә.Г.Булатов иптәшләр катнаштылар һәм чыгыш ясадылар. Җыелышта шулай ук район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев һәм "Нурлат" агрофирмасы генераль директоры Р.С.Чахмахчев катнаштылар.

***

Шул ук көнне шундый ук эчтәлектәге җыелыш **Хафизов исемендәге** хуҗалыкта да булды. Хафизов исемендәге КХА рәисе итеп **Әнәс Нәбиуллович Рәхмәтуллин** сайланды. Җыелышта район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Ю.В.Терентьев һәм хакимият башлыгының беренче урынбасары - авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ф.М. Дәүләтшин катнаштылар.

## ДИРЕКТОР АЛЫШЫНДЫ

9 декабрь көнне "Нурлат" агрофирмасының **дуңгызлар симертү буенча автомат- комплексында** гомуми җыелыш үтте. Анда автомат- комплекс директоры М.М. Сабитов шәхси гаризасы нигезендә вазифаларыннан азат ителде. Комплекс директоры итеп "Нурлат" агрофирмасы генераль директоры Р.С.Чахмахчев карары нигезендә моңарчы шул ук агрофирманың Синдряков исемендәге хуҗалыгында баш бухгалтер булып эшләгән **Надежда Ивановна Храмова** билгеләнде.

### *"Чуваш сандугачы - III"*

## ЙОМГАКЛАУ ТУРЫ - МАРТТА, НУРЛАТТА



Безнең үзешчән башкаручылар "Чуваш сандугачы - III" республика смотр - конкурсының декабрь башында Алексеевскида үткән зона этабында уңышлы чыгыш ясадылар. Шулай итеп, алар конкурсның мартта Нурлатта узачак йомгаклау этабында катнашу хокукын яуладылар. Алты районнан килгән 200дән күбрәк башкаручы арасыннан йомгаклау турына бездән Андреевка сандугачлары Татьяна Колесникова һәм Зоя Абрамова, Аксумла мәдәният йортыннан Сергей Ендиряков, "Родник" халык ансамбле солисты Надежда Митянина һәм шул ук ансамбльдән Галина Степанова белән Людмила Перепелкина дуэты, "Росинка" халык җыр һәм бию ансамбле үтте. Безнең конкурсантлар йомгаклау этабында да (үз өеңдә сер бирү килешми дә бит инде) шулай ук уңышлы чыгыш ясарлар дип ышанабыз.

**М.ПАРУКОВА.**

### *Инвалидлар декадасы тәмам*

## ХӘТЕРНЕҢ ҖУЕЛМАВЫ - ЙӨРӘККӘ ШИФА

Быел безнең пенсионерлар 1991 елда БМОның Генераль Ассамблеясы карары буенча игълан ителгән өлкәннәр көнен сигезенче тапкыр билгеләп үттеләр. Махсус карар тикмәгә генә кабул ителмәгәндер, күрәсең, өлкәннәр һәм инвалидлар проблемасы бөтен дөньяда да актуаль бүген.

Бу көнгә Нефтьчеләр урамының 54 фатирлы йортында яшәүче пенсионерлар өчен яхшы бүләк килде: ниһаять, табигый газ яна башлады. Ихластан сөенгән өлкәннәр "Нурлатнефть" НГДУсы начальнигы М.М.Хуҗин һәм "Татнефть - Нурлатнефтеразведка" начальнигы А.С.Насолдинга олы рәхмәтләрен белдерделәр.

4нче декабрьдә инвалидлар традиция буенча НГДУның конференц - залына чакырылдылар. Анда профком рәисе О.Н.Лизунов һәм НГДУ начальнигы урынбасары Д.Н.Вәлиев өлкәннәрнең сорауларына җавап бирделәр, аннары "Яшьлек" кафесында оештырылган чәй табынына җыелыштылар. Озак еллар буена иңгә - иң куешып эшләгән, нефть чыгару эшенә иң яхшы елларын, сәламәтлекләрен биргән коллегалар белән очрашу күңелләргә хуш килде. Хушлашканда һәркемгә ашамлык пакетлары бирелде һәм махсус автобус ярдәмендә һәркем өенә озатылды.

Бу мәкаләмдә мин тагын олы җанлылык, игелеклелек һәм ихлас күңелдән игътибар күрсәткән РКЦ управляющие А.К.Сафиуллинага, "СБС - Агро"да күп еллар баш бухгалтер булган В.Н.Семеновага, "Девон - Кредит" банкы филиалы управляющие Н.Г.Сәләховага зур рәхмәтемне белдерәсем килә. Озак еллар буе алар без, ветераннарны (мин банк системасында 30 ел эшләдем) онытмыйлар, чәй табынына чакыралар, кайгылар һәм шатлыкларыбызны бүлешәләр. Шулай ук 547нче ПМК хезмәткәрләре дә даими рәвештә җылы теләкләр белән котлау кәгазьләре җибәрәләр. Барысына да рәхмәт.

Менә шулай, сүз һәм эш белән бер - беребезгә ярдәмләшеп тынычлап ял итәбез. Хәтердән сызып ташланмаганлыгыбызны тою авыр вакытларны да җиңәргә ярдәм итә.

**О.ШИГОНЦЕВА,**
**НГДУның ветераннар советы члены.**

## «ДУСЛЫК»КА ЯЗЫЛУ БАРА

***1999 елның беренче яртысы өчен "Дуслык" ("Дружба", "Туслах") район газетасына язылу бәясе - 25 сум 20 тиен. Бөек Ватан сугышында катнашучыларга һәм инвалидларга, Әфган сугышында булучыларга, Чернобыль атом электр станциясендәге фаҗига нәтиҗәләрен бетерүдә катнашучыларга тиешле документлар нигезендә 50 процент ташлама ясала.***

# АНА БӘЙРӘМЕ

*Әни кулларына тиңләр нәрсә бармы,*
*Алар - җирнең асыл энҗесе.*
*И, әнием, син иманым минем,*
*Гомерем моңы, күңелем көзгесе.*

Быел беренче тапкыр Ана бәйрәме көне үткәрелә дигән хәбәр яшен тизлегендә авылга таралды. Чакыру алган күп балалы аналар, киенеп - ясанып, бәйрәм рухында мәдәният йортына ашыктылар. Күңелле музыка уйный, аналарны олылап мәдәният хезмәткәрләре каршы ала. биш һәм аннан да күбрәк бала үстергән аналар безнең авылда 69 икән. Әйе, безнең әниләребезнең төрлеләре бар: яшьләре, чибәрләре, өлкән яшьтәгеләре, саулыкка туймаганнары. Элеккеге саулыкларын югалткан, йөзләрен җыерчыклар каплаган әниләребез дә бар. Заманында алар кемнәр генә булып эшләмәгәннәр, нинди генә авыр хезмәт куймаганнар. Ә. Камаева - тракторчы, Н.Садыйкова, Х.Морадыймова - савучылар, Н.Яруллина, Ә.Хөснетдинова - шикәр чөгендере үстерүчеләр. Яшь буынны тәрбияләүдә дә безнең әниләребез зур хезмәт куйдылар. Медицина хезмәткәре П.Фролова, элеккеге китапханәче Р.Мостафина, укытучылар К.Ибраһимова, Р.Борһанова да бәйрәмгә чакырулы иделәр.

Кереш сүз белән бәйрәмдә К.Мораса җирле үзидарә Советы рәисе А.В.Ибраһимов чыгыш ясады. Ул бүгенге болгавыр заманда аналарның, әбиләрнең гаиләдә искиткеч зур көчкә ия икәнен әйтте. Музей хезмәткәре Г. Садретдинова, мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Р.З.Борһанованың да чыгышлары гаять гыйбрәтле иде. Аналар аларның чыгышларын тыңлаганда узган гомер юлларын искә төшереп, сагышланып та утырдылар. Әниләр бәйрәме җыр, бию белән аралаштырып һәм чәй табыны артында озак барды. Алар һәммәсе дә саубуллашканда зур рәхмәт хисе белән таралыштылар.

**Т.МИНГӘРӘЕВА,**
**китапханәче.**

## БАЛАЛАР ӘНИЛӘРГӘ ОХШЫЙ ИКӘН

Быел беренче тапкыр Татарстанда 29 ноябрь Әниләр көне буларак билгеләп үтелде. Зирекле урта мәктәбенең VII класс укучылары әниләрен мәктәпкә чакырып "Әни һәм мин - сәламәт гаилә" дигән девиз астында тамаша - уен үткәрделәр.

Әниләргә бәйрәм күчтәнәче итеп укучылар үз көчләре белән әзерләгән кечкенә генә концерт күрсәттеләр. Шигырьләр сөйләделәр, җырлар җырладылар.

Бәйрәм кичәсенең икенче өлешендә барлык әниләр матур киемнәрен спорт киемнәренә алыштырдылар. Укучылар - бер, әниләр икенче команда булып "Күңелле старт" уены үткәрделәр...

Әниләребез бик җитез булып чыктылар - зур аерма белән җиңүгә ирештеләр. Укучылар да битараф калмады: әниләрне чәй эчәргә чакырдылар. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Р.Ә. Әхмәтованың: "Булдыклы укучылар каян килә дисәк, аларның әниләре шундый икән", -дигән сүзләре дә урынлы булды.

**Хәлим ӘЛИМОВ,**
**Зирекле авылы укытучысы.**

## ХАТЛАР ЯЗДЫМ УТЫРЫП...

*Мәгариф яңалыклары*

## ӨЙРӘТӘЛӘР МӘКТӘПЛӘРДӘ...

Әйе, күп нәрсәгә өйрәтәләр мәктәпләрдә укучыларны. Ә менә мәктәптә укытучыларның да күп нәрсәгә өйрәнүе - туктаусыз эзләнүе, осталык, тәҗрибә туплавы турында бәлки әле күпләр бөтенләй хәбәрдар түгелдер. Төрлечә бара ул тәҗрибә уртаклашу: ачык дәресләр аша, индивидуаль киңәшләр, методик берләшмә эше аркылы. Шәһәрнең 1нче мәктәбендә, мәсәлән, быел өйрәнү - остаруны нәтиҗәле итү максатында 1 декабрьдән тәҗрибә уртаклашу айлыгы игълан иттеләр. Бу айлыкның максаты - мәктәпнең иң дәрәҗәле, эзләнеп эшләүче укытучылары тәҗрибәсе нигезендә яшь укытучыларга педагогик осталык дөньясына юл күрсәтү, киңәш бирү, ярдәм итү. Айлык планына ачык дәресләр белән бергә, класстан тыш чаралар да кертелгән.

Тәҗрибә айлыгы актив кына башланып китте. Берничә көн эчендә әйдәп баручы укытучы В.Л.Динеева 10 "Г" классында физикадан, Ф.Г.Алькова 5"В" классында инглиз теленнән гаҗәеп кызыклы дәресләр бирергә өлгерделәр инде. Татар теле укытучысы Г.С.Вәлиуллинаның 6"Г" классында биргән дәресе дә яшьләр өчен күп нәрсә алырлык иде. Ә менә Е.И.Казаева бик күңелле итеп класстан тыш чара күрсәтте.

Айлык әле башланды гына, якын көннәрдә күп кенә өлкән укытучылар яшь коллегаларына практик ярдәм булырлык дәресләр бирәчәкләр, аларның дәресләрендә дә катнашачаклар әле. Тәҗрибә шулай, бергә - бергә эшләгәндә тагын да мулдан туплана бит ул!

## ҖЫЛЫЛЫК ПОДЪЕЗДДАН ЮККА ЧЫГА

Кышкы салкыннарда кешенең төп игътибары табигый рәвештә җылыга юнәлә. Урамда күшегеп кайтканнан соң өйләребездә салкын һава каршы алса, кәеф төшә, яшисе килми: өйдә һәрвакыт җылы булуын телибез. Кызганычка каршы, кайбер кешеләр шундый теләктә калуларына карамастан, подъездларда җылылыкны саклауга битараф караштa торалар. Ә бит подъезд - ул өйнең бер өлеше. Өйдән ашыгып чыкканда, подъезд ишекләрен ябарга кирәклеген онытып та җибәрәләр күбесе. Нәтиҗәдә җылыту батареяларында су туңып, җылылык системасында өзеклек килеп туа. Кышның әле беренче ае гына, ә Нурлат җылылык челтәре предприятиесеннән Е.П.Матавин бригадасы Кормыш микрорайонындагы 5 катлы йортларның подъездларында шартлаган 6 батареяны системадан өзде инде. Хуҗасызлык аеруча Совет урамының 189нчы йортында (аз санлы гаиләләр йорты) хөкем сөрә.

Авыр икътисадый шартларда да шәһәрне җылылык белән тәэмин итү өчен көчләреннән килгәннең барысын да кулланган җылылык челтәре коллективы исеменнән халыкка, бигрәк тә күпфатирлы йортларда яшәүче халыкка мөрәҗәгать итәсем килә: җылылыкның бәясе бик кыйммәткә төшә, ә аны саклау сезнең кулда.

**Ф.ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
**җылылык челтәре предприятиесе инспекторы.**



*Бу рәсемдә сез Егоркино урта мәктәбеннән бер төркем укытучыларны күрәсез. Методист укытучы Анатолий Петрович Магинның педагоглык стажы утыз елдан артып китте инде. Рус теле һәм әдәбияты укыта ул. Галина Владимировна Терентьева мәктәп директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары булып тора. Мәктәптәге иң кызыклы чараларны оештыруда ул башлап йөри. Элегрәк 12 ел буе пионер вожатые булып эшләгән иде. Галина Владимировна читтән торып Чуваш дәүләт университетында укый.*

*Рәсемдәгеләрнең өченчесе - Людмила Алексеевна Григорьева башлангыч классларда эшли. Чирек гасырдан артык гомерен балаларга белем һәм тәрбия бирүгә багышлаган педагог шулай ук методист укытучы исемен лаеклы йөртә. Директорның уку - укыту эшләре буенча урынбасары Антонина Алексеевна Белованың биредә эшли башлавына да ике дистә елдан артып китте инде. Шунысын да әйтергә кирәк, алар барысы да - заманында шушы мәктәптә укып чыккан кешеләр.*

**Н.АЗИЗОВ фотосы.**

## КӨНДӘШЛӘР - МИЛИЦИЯ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ

***Тормышта шулайдыр, дип уйлый күрмәгез тагын. Бу бары "Брейн - ринг" ярышларында гына. .***

Шәһәрнең 4нче мәктәбе укучылары. район эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре командасы белән ярышырга күптән теләк белдергән иделәр инде. Ниһаять, узган җомга көнне ике команда да тупланып, үзләрен белем һәм тапкырлыкта сынарга чыкты. Мәктәпнең 10 - 11 класс укучыларыннан торган "Отпетые мошенники" командасын Л.Кудряшова җитәкләде, милициялеләрнең "Улица разбитых фонарей" командасы капитаны А. Трофимов иде.

"Брейн - ринг" бик мавыктыргыч барды. Разминка өлешендә ярышучылар 1 минутта 8 сорауга җавап биреп өлгерергә тиеш иделәр. Сораулар җинаять, гражданлык кодексларыннан алынган җитди характерда булса да, укучылар, үзләренең киң мәгълүматлы булуларын күрсәтеп, өстенлекне үз кулларына алдылар. Төрле ситуацияләргә квалификацияле бәяне дә алар бик оста бирделәр. Ә менә ярышның детектив өлешендә милиция хезмәткәрләренең практик күнекмәләре җиңде һәм бу өлештә алган инициативаны алар "Үземә - үзем режиссер" ярышында да кулдан ычкындырмадылар: юмор, музыкаль һәм артистлык сәләтләрен дә күрсәттеләр. Шулай итеп, ике команда да 253,5әр очко җыеп, ярыш тигез исәп белән тәмамланды. Ни гаҗәп - мондый нәтиҗәгә берәү дә борчылмады, чөнки ярыш һәр ике як өчен дә чын бәйге генә түгел, ачышлар да китерде бит. Әйтик, милиция хезмәткәрләренең коры тәртип сакчысы гына булмыйча, юморга, җыр - биюгә сәләтле, киң эрудицияле шәхес булуын күп укучылар шунда гына белделәр. Милиция хезмәткәрләре дә бүгенге 10 - 11 класс укучыларының белем дәрәҗәсе җитди көндәшлек итәрлек булуына шатланып гаҗәпләнделәр. Моннан соң аларның башка ситуацияләрдә очрашуы да үзара хөрмәткә нигезләнер дип ышанасы килә.

**С.НУРУЛЛИНА.**

## САУЛЫГЫМНЫ КАЙТАРДЫЛАР

Тормыш безне ничек кенә сынамый... 15 октябрьдә мин каты авырып киттем. һәм инде аякка басасыма өметемне дә өзгән идем - аякларым бөтенләй йөрмәс булды. Әмма район үзәк сырхауханәсе табибы З.П.Веренцова миндә сәламәтләнүгә өмет уятты. Дарулар белән генә түгел, үзенең күңел җылысы һәм игътибарлылыгы белән дә дәвалый ул. Ә авыру кеше өчен аның соңгылары бигрәк тә кыйммәт бит. Неврология бүлеге коллективына ихлас күңелдән тазалык, озын гомер һәм гаилә иминлеге телисе килә.

**Р.ПАЛЬКЕЙКИНА.**
**Нурлат шәһәре.**

## БУРЛАР ЙОКЛАМЫЙ, САКЧЫЛАР УЯУ

Быелның 13 ноябрендә төнге сәгать 1ләр тирәсендә ведомстводан тыш сак бүлеге хезмәткәрләре Совет урамының 183нче йорты янында "Жигули - 21063" маркалы машинаны "чишендерергә" азапланган гражданин З.ны күреп алалар. Ул тоткарлана. Тикшерү бара.

Шул ук бүлек хезмәткәрләре 18 ноябрьдә үткәргән рейд вакытында "Сөлчә" һәм "Тәрнәс" хуҗалыкларында 20 литр сөт һәм 60 кг. ашлык урлаган 9 кеше тотыла.

20 ноябрьдә төнге сәгать 2дә бүлек хезмәткәрләре Гыйматдинов урамында үсмерләрне тоткарлыйлар. Алар 8 сыйныф укучылары булып чыга. Сумкаларын тикшергәндә, аннан отверткалар һәм тимер пычкысы табыла. Аларның шулай соңлап кая юл тотканлыкларын милициянең балалар бүлмәсе инспекторлары ачыклар инде.

21 ноябрьдә төнге сәгать 2дә гражданин А. юл кырыенда торган иясез "ВАЗ - 2106" машинасын күреп ала. Ул машинаның тәгәрмәчләрен салдырырга ниятләгәндә генә янына бүлекнең 552нче экипажы килеп чыга һәм аны вакытлыча тоткарлау изоляторына илтеп тапшыра. Тикшерү бара.

**А.ЛОГИНОВ,**
**ведомстводан тыш сак бүлегенең өлкән инспекторы, милиция майоры.**

***Бүген телевизорны сүндереп, көндәлек мәшәкатьләрне, борчуларны һәм заманның авырлыгына зарларның барысын да ташлап, файдалы китап укый яки күзгә - күз карашып сөйләшеп утыра торган яшь гаиләләрне күз алдына китерүе мөмкин түгел инде.***

# САК БУЛЫГЫЗ, ТЕЛЕВИЗОР!



Шундый күркәм гадәтләр 1917нче елгы Октябрь инкыйлабыннан соң юкка чыкты. Гаиләдә әхлакый тәрбия, рухи кыйммәтләр турында төшенчә бирүче дин хур ителде, шуның белән бергә тормышның мәгънәсе турында уйланулар, ата - анага карата изге хисләр, олыларны хөрмәт итү, кылган гамәлләргә җылы мөнәсәбәт тә югалды яки ясалма төс алды. Большевиклар идеологиясе бөтен көченә дин, мәчет, чиркәү белән актив көрәшкә чакырды. Нәтиҗәдә без рухи яктан җимерелүгә дучар ителдек, бигрәк тә бүген, үзгәртеп кору дигән чорда караклык, дәүләт милкен талау, көчләү, урлашу, бигрәк тә “халык бәхетен кайгыртып йөрүчеләрнең” ялганы тормышта гадәти хәлгә әйләнде. Гаилә тәрбиясе ашату, киендерү кебек ихтыяҗи гамәлләргә генә кайтып калды. Халык сайлап куйган хөкүмәт тарафыннан стресс хәленә китерелгән мәктәп тәрбияләү функциясен үти алмый башлады. Бүген кем тәрбияли соң безне, кем “бәхетле киләчәккә” алып бара? Чиркәү, мәчетләр буш...

Хәер, бар безнең “тәрбиячебез”, аның урыны - өебез түрендә. “Тылсымлы әрҗә” әтиебезне һәм әниебезне дә, мәктәпне дә, кешелекнең мең еллар буена тупланган рухи байлыкларын да алыштырды... Беренче һәм икенче каналларңы гына ачыгыз - яңа идеология белән анда таныша аласыз. ОРТ һәм РТР җитәкчелекләрендә “акыллы” гына абзыйлар утыралар, безне ничек тәрбияләү серләрен менә алар беләләр инде. Бу тапшыруларның кайбер “җәүһәрләре”н генә искә аласы килә. “Золотая лихорадка”. Яшь кино сөючеләр кумиры Ярмольник урта гасыр мәгарәсенә охшаган бүлмәдә әллә нинди күз күрмәгән рәшәткәләрдә маймылларча сикереп йөри һәм бертуктаусыз “бары тик алтынның гына бәясе бар, калган бар нәрсә - юк”, дип тукып тора. Уйнагыз, күп алтын отарсыз!

“Угадай мелодию”. Алып баручы тантаналы рәвештә “Бүген сум долларга (франкка, латка, фунт стерлингка һ.б.) тиң дип хәбәр итә. Тамашачыларда бу “бәяләү” кыргый авазлар тудыра.

“Сам себе режиссер”. Тапшыруда җыела алмыйча шаркылдап көлү тавышы тынмый: чираттагы “киношедевр”да чираттагы егылу сурәтләнә. Балалар, әбиләр, ир - атлар - һәммәсе дә егыла. Алып баручы аңлавынча, бу бик көлкеле. Бүләккә: “Менә сезгә (фирманыкы) безнең спонсорыбыздан “маечка”, фәләннән торт”. Призлар, бүләкләр... Җәмгыятьне, аеруча яшьләрне максатчан рәвештә таркату бара. Акча, доллар, баю культы алга сөрелә - бу тапшыруларда да шул чир иң башта тора. Бушлай гына яшәргә өйрән, диләр уен характерындагы 10лап тапшыру. "Лотто - миллион" үзе генә дә ни тора. “До 16 и старше”... Алып баручылар йотлыгып - йотлыгып кинойолдызларның шәхси тормышыннан оятсыз эпизодлар сөйлиләр. Гайбәтләр, имеш - мимешләр... Ә менә яшүсмер кыз оялмыйча үзенең мәхәббәт маҗаралары турында сүз куерта. Бу тапшыру яшьләрне азатлыкка өйрәтә диләр. Ә минемчә, бу аларны йөгәнсезләндерә, азгынлыкка, әхлаксызлыкка өнди.

Ә “ачылу маска”сы! Бер кыз байлыкка кызыгып Германиягә китә һәм анда фахишә ролен “үзләштерә”. Яшь тамашачылар тын да алмыйча тыңлыйлар аны. “Кайчак 30 ар клиентка хезмәт күрсәтергә туры килде”,- ди тегесе, әмма сифилистан кала бу “командировка”дан берни дә алып кайта алмый. Сифилистан Россиядә дәвалыйлар.

Күпләр яраткан “Утреняя звезда” тапшыруын алып баручы Ю. Николаевның зәвыгы да аксый кайчак. Сәхнәдә озын декольте белән күлмәк кигән нәни “Йолдыз” мәхәббәт турында җырлый, ә гәүдәсен Пугачева көнләшерлек итеп селкетә. Бу баладан кем чыгар?

... Атаклы рус җырларын башкаручы Людмила Рюмина да киеменә яңалык кертә: борынгы рус күлмәгенең алдында булдыра алган кадәр югарыдан идәнгә кадәр ярык ясаган. Тамашачыга рус җырының “тирәнлеген” аңларга бик ярдәм итә бу.

...Клиплар. Тавышсыз - нисез җырчыларның башкаруына эротик эчтәлекле картиналар кушыла.

Бер танылган җырчы нигәдер хатын - кызлар тавышы белән җырлый, ә үзе мескен кәҗәне каядыр алып бара. Бу бик талантлы клип, диләр.

Реклама... “Мин куркыныч булмаган сексны сайлыйм!" диләр кызлар күзләрен зур ачып. Подгузниклар, "канатлы" прокладкалар өметсезлек хисе тудыралар. Ниндидер явыз, рәхимсез пычак, әйтерсең лә, безнең җаныбызны, рухи дөньябызны тапый. Әллә ходай бәхетсез Россиягә бөтенләй арты белән борылды микән?

**В.ПОСЕЛЕННОВ.**

# *САКСЫЗЛЫК ЯХШЫГА ИЛТМИ*



Анализ күрсәткәнчә, агымдагы елның 10 аенда тимер юлларда хәрәкәт иминлеге мәсьәләсендә хәл бик яхшыдан түгел. Юл - транспорт вакыйгаларының саны былтыргыга караганда 15 процентка артты. Тәртипне нигездә юл хәрәкәте кагыйдәләрен үтәмәүче шоферлар иң күп боза. Әйтик, быелның 8 октябрендә Куйбышев тимер юлының Лучинская станциясенең Грабово тимер юл кичүендә хуҗалык поезды “Жигули”га бәрелде. Бәхеткә, шофер һәм пассажир сикереп төшәргә өлгерәләр, әмма машина эшкә яраксызга чыга. 16 июньдә Октябрь тимер юлының бер кичүендә электр поезды белән ЗИЛ машинасы бәрелеште. Машинист поездны туктатырга тырышып карый, әмма өлгерә алмый, нәтиҗәдә шофер һәм ике пассажир һәлак булды. Шул ук көнне Мәскәү тимер юлының бер перегонында электр поезды арба таккан “Беларусь” тракторы белән бәрелешү аркасында поездның беренче вагоны рельстан чыккан, ике кеше зыян күргән: тракторчы авыр хәлдә сырхауханәгә китерелгән, пассажиры үлгән. Җитмәсә, тракторчы исерек тә булган һәм юл хәрәкәте кагыйдәсен бозган.

15 сентябрьдә Сахалин тимер юлында эшче поезд КамАЗ машинасы белән бәрелеште, нәтиҗәдә мотовозга зыян килде, гомуми зыян 5,6 мең сумлык булды. Һәм мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. 10 айда гына да тимер юлда 159 юл - транспорт вакыйгасы булып, 125 кеше каза күрде, 48 кеше үлде. Шуңа да без руль артындагыларга гаять тә игътибарлы булуларын, тимер юл кичүләре аркылы чыкканда үтә сак эш итүләрен сорап мөрәҗәгать итәбез. Авто һәм башка хуҗалык җитәкчеләре дә техниканың нинди кешеләр кулына тапшырылуын, бигрәк тә пассажирлар йөртүче машина шоферларының квалификациялелек һәм эшлеклелек сыйфатларын тагын бер тапкыр күздән кичерергә тиешләр. Ә тимер юлларда саксызлык бер дә яхшыга илтми, киресенчә, гаять кыйммәткә төшә, бик үкенечле нәтиҗәләргә китерә.

**А.КАРПОВ,**
**Димитровград юл дистанциясе начальнигы.**

***<u>Төрек ашлары</u>***

## ЯШЕЛЧӘЛЕ ТӨРЕК ПЫЛАВЫ

***<u>Кирәкле әйберләр: 2 стакан дөге, 3 стакан су, 3/4 стакан үсемлек мае, тоз, бер данә кишер, 1 стакан туңдырылган яшел борчак, ярты көлтә укроп.</u>***

***ӘЗЕРЛӘҮ ЫСУЛЫ:***

Дөгене чистартыгыз, юыгыз һәм сөзегез. Кишерне кечкенә шакмаклар рәвешендә турагыз. Кәстрүлдә үсемлек маенда өч минут кыздырыгыз. Өстенә дөге салыгыз. Агач кашык белән болгатып, дөгене биш минут дәвамында кыздырыгыз. Шуннан соң өч стакан җылы су өстәгез. Тоз сипкәннән соң кәстрүлне капкач белән каплагыз. Башта куәтле утта тотыгыз. Дөге бүртә башлагач, кәстрүлгә туңдырылган яшел борчак салыгыз. Шуннан соң утны кыса төшегез. Пылау пешкәннән соң аны ябык кәстрүлдә бераз тотыгыз. Томалап тотканнан соң өстенә вакланган укроп сибегез. Шуннан соң пылауны туглап, табынга куярга мөмкин.

# БЕЛДЕРҮЛӘР

### САТАБЫЗ

**Тотылган, кием шкафсыз стенка.** Тел.: 5-15-30.

***

**Телевышка янында гараж.** Адрес: Гагарин ур., 26 -16.

***

**К.Маркс проспекты буенча (ветераннар йорты янында) капиталь гараж.** Тел.:5-13-12.

### АЛМАШТЫРАБЫЗ

**Соры төстәге, 1993 елгы ГАЗ - 31029 ны - иткә.** Киекледә тел.: 3-31-55.

### ТӨРЛЕСЕННӘН

**Аэропорттагы ресторан Сезне Яңа ел бәйрәмен менә дигән иттереп үткәрергә һәм ял итәргә чакыра. Алдан заявка биреп куегыз.** Тел.: 5-43-56.

***

**Әлмәт нефть институты студенты Владимир Ильич Кузьмин исеменә бирелгән РН - 97 -61 зачет кенәгәсен югалу сәбәпле гамәлдән чыккан дип исәпләргә.**



***Н.АЗИЗОВ фотосы.***


# ЭКСПРЕСС - ҮЗӘК



***ТОВАРЛАР ҺӘМ ХЕЗМӘТЛӘР ТӘКЪДИМ ИТӘ:***

- компьютерлар һәм оргтехника (ксерокслар, факслар һ.б.)
- персональ ЭВМнарга һәм оргтехникага комплектлаучы һәм тотыла торган материаллар
- локаль хисаплау челтәрләрен ахыргача урнаштырып бирү
- компьютерлар һәм оргтехникага гарантия чорында һәм аннан соң хезмәт күрсәтү
- персональ ЭВМ һәм оргтехниканы ремонтлау һәм заманчалаштыру
- көнкүреш аппаратуралары (телевизорлар, аудио - һәм видео магнитофоннар, видеокамералар, музыкаль үзәкләр һ.б.) ремонтлау
- ксерокүчермәләр алу хезмәте (А4 форматы)
- текстлар җыю һәм бастырып бирү
- персональ ЭВМнарда сәгатьләп эшләү мөмкинлеге
- фототасмаларны ачыгайту һәм төсле фотолар ясау (10 x15 форматлы)
- документларга мизгел эчендә 2,5 x 3,5 һәм 3,5 x 4,5лы аклы - каралы һәм төсле фотолар ясау
- фототоварлар (тасмалар, батареялар, альбомнар, фотоаппаратлар һ.б.)
- техник һәм матур әдәбият.

***Шартнамәләр төзи:***

- персональ ЭВМнарга техник хезмәт күрсәтүгә
- программалар белән тәэмин итү һәм хезмәт күрсәтүгә
- махсус багланышлы программалар эшләү һәм аларны кертүгә.

***Республика НИОКР фондының терәк предприятиесе НИОКР эшләү, рәсмиләштерү һәм кулланылышка кертү буенча барлык хезмәтләрне дә күрсәтә.***

***Аксеновның Бизнес Мәктәбе***
***Казан филиалы***
***түбәндәге курсларда укырга тәкъдим итә:***

- Персональ ЭВМ (Windows,Ofisse 97) операторлары
- BASIC телендә программалау нигезләре
- FOXPRO телендә программалау нигезләре
- PASCAL телендә программалау нигезләре (11нче класс укучылары өчен)

Нурлат шәһәрендә Мәктәп ур., 8 адресы буенча Экспресс - Үзәккә иртәнге 8дән кичке 6га кадәр мөрәҗәгать итәргә (төш вакыты көндезге 1дән 2гә кадәр).

Белешмәләр өчен тел.: 5-37-51

***Экспресс - үзәк ярымүткәргечле төсле телевизорларның кинескопларын калдык буларак кабул итә.***



МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр:Нурлат район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Нурлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19. Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм җаваплы сәркәтип - 2-18-67, авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар, хатлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***ГазетаТатарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясендә офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2361 данә. 4736